Совет Старочукалинского
сельского поселения Дрож-
жановского муниципального
района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Иске Чокалы
авыл җирлеге Советы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12

===========================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы авылы

26 июль 2023 ел № 28/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 23.05.2023 №27/1 карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**9 статьяның 5 пунктына** «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

**19 статьясындагы 3 пунктны түбәндәгечә бәянитәргә:**

“1) коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Иске Чокалы авыл
җирлеге Башлыгы: Р.Р.Низамутдинов